2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Карар

2023 елның 21 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында“ 06.10.2003 елдагы 131-03 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында“ 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тагай авылы Абалач авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның җыены карар итте:

1. 2024 елда Менделеевск муниципаль районының Тагай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге белем бирү студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

– су насосын сатып алу-2 данә.

- Тагай авылында авыл эчендәге юлларны тоту (кышкы чорда кардан чистарту)

-Тагай авылында һәйкәл территориясендә Үлемсез полк стендын ясау

-Тагай авылында мәгълүмат стенды ясау

- Агачларны кисү эшләре

3. Тагай авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://mendeleevsk.tatar.ru «Абалачев авыл җирлеге»бүлегендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Абалач авыл җирлеге башлыгы Р. Н. Сиражетдинов